**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында наркотикларга каршы комиссиянең персональ составына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында наркотикларга каршы комиссия эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре турында» 2007 елның 25 декабрендәге ПУ-698 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2008 елның 29 апрелендәге ПУ-179 номерлы, 2009 елның 5 мартындагы ПУ-123 номерлы, 2009 елның 17 апрелендәге ПУ-212 номерлы, 2009 елның 22 июнендәге ПУ-343 номерлы, 2010 елның 19 маендагы ПУ-330 номерлы, 2010 елның 11 ноябрендәге ПУ-742 номерлы, 2010 елның 31 декабрендәге ПУ-896 номерлы, 2011 елның 26 мартындагы ПУ-158 номерлы, 2011 елның 19 маендагы ПУ-266 номерлы, 2011 елның 15 августындагы ПУ-504 номерлы, 2012 елның 24 гыйнварындагы ПУ-42 номерлы, 2012 елның 20 февралендәге ПУ-125 номерлы, 2012 елның 11 июнендәге ПУ-459 номерлы, 2012 елның 27 сентябрендәге ПУ-786 номерлы, 2012 елның 10 ноябрендәге ПУ-937 номерлы, 2013 елның 9 октябрендәге ПУ-1007 номерлы, 2014 елның 29 декабрендәге ПУ-1183 номерлы, 2016 елның 11 мартындагы ПУ-237 номерлы, 2016 елның 22 августындагы ПУ-715 номерлы, 2018 елның 8 маендагы ПУ-365 номерлы, 2019 елның 19 мартындагы ПУ-174 номерлы, 2019 елның 9 октябрендәге ПУ-614 номерлы, 2020 елның 19 декабрендәге ПУ-856 номерлы һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 7 мартындагы 140 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында наркотикларга каршы комиссиянең (алга таба – Комиссия) персональ составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан Р.З. Галәветдиновны, С.Н. Погодинны, А.В. Хохоринны, Л.Н. Шәйхетдинованы чыгарырга;

б) Комиссия составына кертергә:

Виниченко Владислав Валентиновичны – Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы җитәкчесен (килешү буенча);

Денькин Алексей Юрьевичны – Татарстан Республикасы хәрби комиссары вазыйфаларын вакытлыча башкаручыны (килешү буенча);

Никитин Юрий Сергеевичны – Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе җитәкчесен (килешү буенча);

Комиссия рәисе урынбасары итеп раслап, Садретдинов Дамир Рөстәм улын – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрын (килешү буенча).

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2024 ел, 22 май
№ 377